
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



## Ватанны саклаучылар көне котлы булсын!

№6
Февраль, 2026 г.




Мәктәп үзидарәсе укучылары мәктәпнең барлык ир-ат хезмәткәрләрен 23 февраль белән чын күңелдән котлый!

Сезгә профессиональлегегез, ярдәмегез һәм безгә үсәргә һәм үсәргә ярдәм итүче акыллы киңәшләрегез өчен рәхмәт белдерәбез. Сезнең җаваплылыгыгыз, көчегез һәм ышанычлылыгыгыз — үсеп килүче буын өчен үрнәк.

Ныклы сәламәтлек, иминлек, яңа казанышлар һәм барлык башлангычларда уңышлар телибез! Һәр көн шатлык, илһам һәм күңелле сюрпризлар китерсен!

**С Днём защитника Отечества!**

Ученики школьного самоуправления от всего сердца поздравляют всех работников-мужчин нашей школы с 23 Февраля!

Благодарим вас за профессионализм, поддержку и мудрые советы, которые помогают нам расти и развиваться. Ваша ответственность, сила и надёжность — пример для подрастающего поколения.Желаем крепкого здоровья, благополучия, новых достижений и успехов.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Ватанны саклаучы-лар көне | 1 |
| Каһарманнар эзеннән | 2 |
| Без аны каһарман буларак беләбез | 3 |
| Школьные новости | 4 |
| Туган телем—иркә гөлем | 5 |
| Канатлы дуслары-Бызга ярдәм | 6 |

# Каһарманнар эзеннән

Хәрби-патриотик тәрбия безнең мәктәп эшчәнлегенең төп юнәлешләренең берсе булып тора.

Әлеге уңайдан, мәктәптә 2014 елның августыннан бирле эшли торган музей эшчәнелеген тәкъдим итәргә була. Андагы экспозицияләр мәктәп тарихы, укучылар, чыгарылыш сыйныф укучылары һәм укытучылар тормышы турында сөйли. Алар арасында хәрби тематикага багышланган экспозицияләр төп урынны алып тора дисәк тә дөрес булыр.

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышына багышланган экспозицияләр игътибарны җәлеп итә. Ул миллионлаган ватандашларыбызның гомерен өзгән коточкыч вакыйгалар турында сөйли. Витринада Бөек Ватан сугышы темасын ачып бирүче төрле әйберләр: фотолар, медальләр һәм орденнар, реликвияләр, киемсалым, газеталардан өзекләр урнаштырылган.

Шулай ук Әфган сугышы тарихы турында сөйли торган позицияләр дә бар. Бу канлы сугышта катнашып гомерен өзгән чыгарылыш сыйныф укучыларыбызның берсе - Марат Лотфуллин хакында истәлекләр белән танышыр вакыт җитте.

Ике елдан соң мәктәп фойесында Марат Лотфуллин исемендәге мемориаль такта ачыла.

Бу тантанага кунаклар, Маратның классташлары һәм геойның әнисе дә килә.

Музейның кайбер витриналарында аның хатлары, комсомол билеты, бүләкләр һәм медальләр бар. 2020 елда безнең мәктәп коллективы Марат Лотфуллинга багышланган "Үлемсезлеккә юл" китабын язып бастырып чыгарды.

2022 елның февралендә Украина территориясендә нацистларны юк итү максатыннан махсус хәрби операция башлана. Музейда экспозиция хәтер китабы рәвешендә эшләнгән, анда СВОда гражданлык бурычын үтәгәндә үз гомерләрен биргән геройларыбыз - безнең чыгарылыш укучыларыбыз турында мәгълүматлар урнаштырылган.

Безнең мәктәп коллективы сугыш кырында булган якташларыбызга ярдәм итәргә тырыша. Шулай итеп, укучыларыбыз, әти-әниләребез һәм мәктәбебез коллективы көче белән фронтка окоп шәмнәре, челтәрле маскировкалар җибәрелде. Укучылар гел фронттагы сугышчыларга хатлар язып торалар.2009 елда Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән мәктәптә кадет сыйныфлары ачу уңаеннан "Ритм" барабанчылар,2016 елның сентябреннән мәктәп базасында Илдус Аскаров җитәкчелегендә "Яшь армиячеләр" отряды оештырыла. Алар , Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм туганнарына ярдәм күрсәтә, зур мәдәни һәм спорт чараларында катнаша.

**Адилә** Гыйләҗетдинова, 8 А сыйныфы



# Без аны каһарман буларак беләбез

2026 ел Хәрби батырлык һәм хезмәт фидәкарьлеге елы дип игълан ителде.

Мәктәп тарихында тирән эз калдырырдай батырларыбызны барлар вакыт җитте, димәк.


Анисимов Сергей Александр улы 1982 елны Арчада туган. Әнисе Лариса Вениамин кызы—фельдшер, әтисе Александр Николай улы—заводта эретеп ябыштыручы булып эшли.

Сергей мәктәптә укыганда үрнәк укучы була. Сыйныфташларының һәм укытучыларның ихтирамын яулый. Теләсә нинди катлаулы ситуциядә дә иптәшләренә булыша. Аларны ярдәменнән калдырмый.

Мәктәпне тәмамлагач, юридик юнәлештә белем алырга дип Арча аграр-сәнәгать һөнәр көллиятенә укырга керә. Өченче курстан соң армиягә китә. Кечкенәдән Ватанны саклаучы булырга теләгән егетнең бу хыялы дәвамлы булып чыга. Гаилә сәбәпләре аркасында ул хәрби хезмәтен тәмамлаганчы ук кайтырга мәҗбүр була. Хезмәт иткән вакытта әтисен югалту хәсрәте тормышында зур борылышка сәбәп була.

Ринат кызы Айгөл белән гаилә коргач, 2004 нче елда уллары Никита, 2008 нче елда кызлары Арина туа.

Бүген без Сергей Алсекндр улын Махсус операциядә хәрби бурычын үтәгәндә геройларча һәлак булган каһарман буларак беләбез. Аның белән горурланабыз.




**Разил** Кәримов, 8А сыйныфы

## Заманча һөнәрләр дөньясында



9 нчы классны тәмамларга бик аз вакыт калып бара. Укучылар алдында: “9 нчы сыйныфны тәмамлагач кая барырга? Укуны кайда дәвам итәргә? Нинди һөнәр үзләштерергә?” - дигән сораулар тудырмый калмагандыр. Әйе, гомерлек һөнәрне сайлау бик авыр эш. Мөстәкыйль яшәргә 14-15 яшьтән үк уйлана башларга вакыт.

24 нче февраль көнне мәктәптә «Арча аграр-сәнәгать һөнәр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем учреждениесе вәкиле Минһаҗев Фәрит Фоат улы катнашында һөнәри юнәлеш бирү чарасы узды. Кунак укучыларны уку йортында алырга мөмкин булган актуаль һөнәрләр белән таныштырды, әзерлек юнәлешләре, укырга керү шартлары һәм чыгарылыш укучыларын эшкә урнаштыру перспективалары турында җентекләп сөйләде.

Очрашу барышында укучылар белем бирү үзенчәлекләре, практик күнекмәләр һәм һөнәри үсеш мөмкинлекләре турында сораулар бирделәр. Чыгыш аудиториядә зур кызыксыну уятты һәм балаларга заманча һөнәрләр дөньясында яхшырак ориентлашырга ярдәм итте.

# Школьные новости

### А ну-ка, парни!

В преддверии Дня защитника Отечества в 3 «Б» классе царила атмосфера азарта и веселья. Для юных защитников было организовано увлекательное соревнование «А ну-ка, парни!».

Мальчики разделились на две бесстрашные команды — «Пограничники» и «Моряки». Ребятам предстояло пройти через непростые испытания, где они продемонстрировали свою ловкость, смекалку, скорость и настоящую командную поддержку. Будущие защитники с честью справились со всеми заданиями, доказав, что готовы к любым трудностям.



Кульминацией праздника стало трогательное поздравление от девочек класса.

### Рыцарский турнир

В рамках празднования Дня защитника Отечества в 4 А классе прошёл необычный «Рыцарский турнир». А организовали его для мальчиков... девочки!



Прекрасные дамы сами придумали сценарий и подготовили испытания для своих рыцарей: конкурсы на ловкость, интеллект и галантность. Ведь защитник во все времена должен быть не только сильным воином, но и благородным человеком. Мальчики с честью выдержали экзамен и были посвящены в рыцари!

Огромное спасибо девочкам за такой душевный подарок и мальчикам — за старание и улыбки. Это был настоящий урок дружбы, который запомнится всем!

21 февраля в 8А произошло необычное событие. Девочки устроили для мальчиков настоящий сюрприз, превратив поздравление с 23 февраля в серьёзные армейские испытания.

С утра ребят ждала самая настоящая медицинская комиссия. Как в военкомате — строго, честно, по-взрослому! Девочки перевоплотились в специалистов и проверили будущих защитников по полной программе:

Терапевт оценил общее состояние здоровья и выносливость Окулист проверил зоркость и внимательность ЛОР испытал слух. А после медиков — настоящая строевая подготовка!

Итог порадовал всех! Каждый мальчик успезаветную отметку «ГОДЕН». А главным подарком стал настоящий Предвоенный билет — символ готовности к любым испытаниям и, конечно, сладкие сюрпризы от девчонок.



# Туган телем—иркә гөлем

1999 нчы елның ноябрендә, Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте.

Беренче мәртәбә ул 2000 нче елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.



Татар теле һәм әдәбияты атналыгы кысаларында Халыкара туган телләр көне уңаеннан "Туган телем-иркә гөлем" исеме астында чаралар оештырылды.Укучылар туган телдә язылган шигырләрне укыдылар,күнгә милли бизәк чигү буенча оештырылган осталык дәресләрендә катнаштылар




Татар теле иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!

Атналык кысаларында “Тукай шигырьләрен яратабыз" исемле кичә уздырылды.Укучылар бөек шагыйребез Габдулла Тукайның шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйләделәр. Һәр укучыга диплом тапшырылды.

«2023-2030 елларга Татарстан



Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы нигезендә «Сәйяр» Республика балалар һәм яшүсмерләр театрлары фестивале үткәрелә. Атналык кысаларында “Сәйяр”исемендәге районкүләм театр фестиваленә конкурска видео төшереп салдык. Бу өзектә Габдулла Тукайның тормыш юлы тасвирланды.Укучылар бик теләп, яратып катнаштылар. Элеге видеоны түбәндәге ссылка буенча кереп карарга була:

https://cloud.mail.ru/public/d1wv/zataChZST

**Гөлнара** Мөбәрәкшина, татар теле методик берләшмә җитәкчесе.



# Укучылар иҗаты

## Канатлы дусларыбызга ярдәм



Кышын кошларга азык табу кыен була. Шуңа күрә мин канатлы дусларга булышырга булдым. Без ял көне этием белән бергә җимлек ясадык һәм аны агачка элеп куйдык. Мин көн дә җимлеккә симәнке сала башладым. Тиз арада аңа кунаклар очып килә башладылар.

Күбесенчә безгә чыпчыклар очып килә. Алар — бик хәрәкәтчән һәм шаяннар. Еш кына азык өчен бер-берсе белән талашалар, уйнашалар. Чыпчыкларның саны көн саен күбәя, әйтерсен лә, алар бер- берсенә, ризык бар дип, хәбәр җибәреп торалар. Алар үзләре коңгырт, кечкенә томшыклары кара төстә икән.

Кыш көнендә кошларга безнең янәшәдә булуыбыз кирәк. Әгәр һәр кешенең җимлеге булса, күп канатлы дуслар салкынлыкны үтә алачак.

Хәзер мин көн дә рәхәтләнеп тәрәзәгә йөгереп барып, бүген безнең җимлеккә нинди кош очып килгәнен карарга тырышам.

**Камил** Сөнгатов, 4Б сыйныфы.

## Кышны озату бәйрәме

Масленица – урыс халкының гореф-гадәт буенча бәйрәм итә торган күңелле кышны озату бәйрәме.

Бу бәйрәм гадәттә февраль азагында яки март башында була һәм бер атна дәвам итә. Масленица – ул кышны озатып, язны каршы алу бәйрәме. Кешеләр бу атнада күңел ачалар, бер-берсенә кунакка йөриләр һәм төрле уеннар уйныйлар. Масленицаның төп билгесе – коймак. Коймак түгәрәк, кызгылт сары төстә, ул язгы кояшны символлаштыра. хуҗабикәләр атна буе коймак пешерәләр һәм аларны төрле тәм-томнар белән ашыйлар. Бүгенге көндә дә Масленица – яраткан халык бәйрәме. Бу көнне паркларда һәм мәйданнарда концертлар, уеннар, коймак бәйрәмнәре үткәрелә.




Һәр елны мәктәптә үткәрелүче әлеге бәйрәмне башлангыч сыйныф укучылары бик көтеп ала. Бу көнне дә, һәр елдагыча, зур әзерлек белән килеп бик матур чыгышлар ясадылар. Аннары бергәләп тәмләп коймак ашап чәй эчтеләр. Хәтердә калырлык бәйрәмнәрнең берсе булды ул. Укучылар гореф-гадәтләрне белеп үссен өчен, мондый чаралар мәктәптә еш үткәрелеп килә.

**Алмаз** Әхмәтханов, 4Б сыйныфы


***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Нафиса Камалова

***Фотокорреспондент*** Зарина Халиуллина

***Корректор*** Диляра Гарифуллина

***Редколлегия*** Зиля Юсупова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы:*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2